# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

## КАРАР
IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2022 елның 28 январе №1 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.10.2021 ел № 81 карары белән расланган муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 45-ТРЗ номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 8 статья өстәргә:

«**8. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Гражданин, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан кулланыла торган җир кишәрлеге мәйданының күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән мәйданына туры килмәве.

2. Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында граждан, юридик зат, шәхси эшмәкәр куллана торган җир кишәрлегенә хокуклар турында белешмәләрнең булмавы.

3. Граждан, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан җир участогын максатчан билгеләнештәге җир кишәрлегеннән файдалануның теге яки бу категориясенә һәм (яки) рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән файдалану төрләренә туры килмәве.

4. Торак яисә башка төзелеш өчен билгеләнгән җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзүгә бәйле рәвештә капиталь төзелеш, төзелеш эшләре алып бару объектлары булмау.

5. Максатчан билгеләнеше буенча кулланылмау яки авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлегенә милек хокукын бозып файдалану сәбәпле җир кишәрлеген тартып алу турында суд карары нигезендә ачык аукцион үткәрү нәтиҗәсендә барлыкка килгән вакыттан соң бер ел үткән булу.

6. Җир кишәрлеген максатчан билгеләнеше буенча файдалану өчен яраклы хәлгә китерү бурычын үтәмәү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасының
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

.